| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

25.06.2020 № 209

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 09.01.2014 № 6 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында билгеләндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы ГТХМда дәүләт граждан хезмәте турында законны гамәлгә ашыру максатларында, 30.12.2004 № 614 «Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.04.2020 № 269 «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында» карары кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының (алда – Татарстан Республикасы ГТХМ) 09.01.2014 № 6 (Татарстан Республикасы ГТХМ 05.05.2014 № 205, 14.12.2015 № 572, 23.05.2016 № 215, 09.04.2019 № 136 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында билгеләндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук

хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә алдагы үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектәге 5 абзацта «табигый һәм техноген куркынычсызлык» сүзләрен «гадәттән тыш хәлләрне кисәтү» сүзләренә алыштырырга;

II бүлекне түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлегенең төп киңәшчесе».

2. Әлеге боерыкны министр урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә һәм Татарстан Республикасы ГТХМ аппаратының дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Бирелгән Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Т.В. Кәримуллин